**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№588**
**03.02.2023**

Башкарма комитетның 2013 елның 16 гыйнварындагы 122 номерлы карары белән расланган мәгълүматтан файдаланучының соравы буенча, аңа Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 16 гыйнварындагы 122 номерлы карары белән расланган мәгълүматтан файдаланучының соравы буенча, аңа Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү процедурасын» сүзләрен «Башкарма комитет эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү процедурасын» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Тәртиптә файдаланыла торган төшенчәләр «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.»;

3) 13 пунктның сигезенче абзацында «Интернет» челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов